Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының
Гаделша авыл җирлеге башлыгы
Карары

2020 елның 12 ноябре № 9

«Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Чистай муниципаль районы Гаделша авыл җирлегенең Чирүле Шонталы авылында гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Чистай муниципаль районының «Гаделша авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2020 елның 25 ноябрендә 09.30 сәгатькә ФАП бинасында Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Гаделша авыл җирлегенең Чирүле Шонталы авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Татарстан Республикасы, Чистай районы, Чирүле Шонталы авылы, Речная ур., 2 нче йорт.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«2021 елда Чистай муниципаль районы Гаделша авыл җирлегенең Чирүле Шонталы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән үзара салым кертүгә, 500 сум күләмендә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризалашасызмы:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, китерү, салу, килешү буенча эшләр өчен түләү)

**«РИЗА»** **«КАРШЫ».**

3. Җыенны оештыручы итеп Чистай муниципаль районының Гаделша авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

4. Чистай муниципаль районы Гаделша авыл җирлеге башлыгының «Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Чистай муниципаль районы Гаделша авылы җирлегенең Чирүле Шонталы авылында гражданнар җыенын билгеләү турында» 2020 елның 30 октябрендәге 6 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләрне күпләп җыелган урыннарда, игълан итү стендларында һәм такталарында элү юлы белән игълан итәргә, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Чистай муниципаль районының
Гаделша
авыл җирлеге башлыгы _________ И.А.Нуретдинов